**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№928**
**21.02.2019**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 бүлекнең 23 пункты, «Күмү һәм җирләү эшләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законның 9 маддәсенең 3 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрнең күләмен раслау турында» 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эшләре турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче, 2 нче кушымталарда каралганча 5 946,47 сум күләмендә расларга һәм 2019 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. 2014 елның 13 августында «Челнинские известия» газетасының 59 нчы санында басылып чыккан Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Горкоммунхоз» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә тарифлар билгеләү турында» 2014 елның 28 маендагы 3096 нчы карары 2019 елның 1 февраленнән гамәлдән чыккан дип таныргга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ә. Кыямовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 21 февралендәге
928 нче карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә
бәяләр
(якын туганнары, ире (хатыны) булган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1500,00 |
| 3. Мәетне (калдыкларны) зиратка илтү | 890,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3556,47 |
| барлыгы | 5946,47 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 21 февралендәге
928 нче карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә
бәяләр
(якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне төрү | 591,47 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 908,53 |
| 4. Мәетне (калдыкларны) зиратка илтү | 890,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3556,47 |
| барлыгы | 5946,47 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова